


**2003 елда Кызылтау урта мәктәбендә авылдашыбыз олуг язучы, тел белгече М.Х.Гайнуллинга багышлап музей ачылды. Әлеге музейны ачуда озак еллар шушы мәктәптә укучылырга математика фәненнән белем биргән, укыту-тәрбия эше буенча директор урынбасары булып эшләгән Татарстанның Атказанган укытучысы Исмәгыйлев Кытдус Сафиулла улының өлеше зур. Кытдус Сафиулла улы музей ачуда үзенең зур эшчәнлеген кертте, башлап йөрүчеләрнең берсе булды. 2003-2006 елга кадәр әлеге музейның җитәкчесе булып эшләде. Музей белән ул җитәкчелек иткән елларда, аның тырышлыгы белән, бик күп экспонатлар тупланды. 2003 елда аның инициативасы белән мәктәбебез М.Х Гайнуллин исемен йөртә башлады. Лаеклы ялда булса да Кытдус Сафиулла улы мәктәп, музей белән даими бәйләнештә, бүген дә күңеле белән мәктәптә - үзенең саллы киңәшләрен бирә, укучыларга теләкләрен җиткерә.**

Музей җитәкчесе Гайнуллина Гүзәл Харун кызы.